ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 13 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 397-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 13 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 397-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы — М.Г. Әхмәтов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2023 елның 20 апреле
№ 1934-VI ДС

Икенче укылышка
әзерләнгән проект

**«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 13 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 13 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 1 – 2; 2011, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2014, № 1 – 2, № 5; 2015, № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2016, № 40 (I өлеш); 2018, № 78 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 өлешнең 1 пунктында «арендалана торган» сүзләреннән соң «күчемле һәм» сүзләрен өстәргә;

2) $4^1$ өлештә «арендалана торган» сүзләреннән соң «күчемле һәм» сүзләрен өстәргә;

3) түбәндәге эчтәлектәге $4^3$ өлешне өстәргә:

«$4^3$. Татарстан Республикасы милкендә булган һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендага ала торган милек өчен кичектереп түләү срогы «Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда, күчемсез милек өчен сигез ел һәм күчемле милек өчен өч ел.

Арендалана торган мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектына арендаланган сатып алына торган мөлкәт өчен түләү тәртибен (берьюлы яисә кичектереп түләү), шулай ук әлеге өлеш нигезендә билгеләнгән чикләрдә кичектереп түләү срогын сайлау хокукы бирелә.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының

13 статьясындагы $4^3$ өлеше нигезләмәләренең гамәлдә булуы (әлеге Закон редакциясендә) кече һәм урта эшкуарлык субъектлар белән алдарак төзелгән, Татарстан Республикасы милкендә булган арендалана торган мөлкәтне сату-алу килешүләреннән килеп чыккан хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Рәисе